**Татар теле - 21 код**
**6 нчы сыйныф I вариант**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Татар теленнән биремнәрне башкаруга 45 минут вакыт бирелә. Тәкъдим ителгән эш 2 өлештән тора.

Беренче өлеш 16 биремне үз эченә ала (1-16), сез алар арасыннан дөрес дип уйлаган бер җавапны сайлап алырга тиеш. Икенче өлеш 4 биремнән (17-20) тора. Әлеге биремнәр текстка бәйле рәвештә башкарыла. Аларга җавапны сез мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга һәм язып куярга тиешсез.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәгез. Аларны үтәү барышында сезнең өчен кыенлык тудырганнары килеп чыкса, әлеге биремне калдырып торып, алдагыларына күчәргә киңәш итәбез. Сез бу биремнәргә, вакытыгыз калган очракта, кабат әйләнеп кайта алачаксыз.

**1 өлеш**

**1.** Кайсы төркемдә **аваз һәм хәреф саны** туры килә?
1) өчен, ат, янәшә
2) гадәт, Агыйдел, сәнгать
3) ямь, дәвер, әһәмият
4) ватык, кагыйдә, гомер

**2. Васыять** сүзендә нинди сузык авазлар бар?
1) а, и, ә
2) а, ы я
3) а, ы, е
4) а, ы, э

**3.** Кайсы төркемдәге сүзләрдә күпнокталар урынына **Ң хәрефе** языла?
1) мә...ге, ти...ләү, иртә...ге
2) боры...гы, ди...гез, тә...кә
3) бәрә...ге, ши...гән, я...гырау
4) ә...кәй, у...ган, я...гыр

**4.** Түбәндәге мисалларда сүзләр үзара **антоним** булган вариантларны күрсәтегез.
1) тагын, яңадан, арт, ал
2) күңел, җан, әҗәт, хаҗәт
3) ару, талчыгу, матур, ямьсез
4) дус, дошман, биек, тәбәнәк

**5.** Кайсы пунктта **фразеологик берәмлекләр рәте** бирелгән?
1) колак торгызу, акылга утыру
2) белем иясе, кычкырып җибәрү
3) тау куышы, миләш яфрагы
4) ватык көзге, авыз турсайту

**6. Миләш чыпчыгы, үги ана яфрагы, тавыш бирү** сүзләре сүз ясалышының кайсы ысулы буенча ясалганнар?
1) сүзләрне кыскарту юлы белән
2) сүзгә кушымчалар өстәү юлы белән
3) сүзләрне тезү ысулы белән
4) болар сүзтезмәләр

**7. Ясалма сүзләр** кайсы төркемдә?
1) сәхнә, күңел
2) язмыш, үлем
3) тана, ихтимал
4) гыйбрәт, тамаша

**8. Сыйфат ясагыч кушымчалар** кайсы төркемдә бирелгән?
1) -тын/-тен, -лап/-ләп
2) -ымта/-емтә, -гар/-гәр
3) -ләтә/-лата, -лаш/-ләш
4) -сыл/-сел, -ык/-ек

9. **Бәйләгеч кушымчалар** кайсы рәттә күрсәтегез?
1) -ның, -нең, -га, -гә, -дан, -дән
2) -лык, -лек, -ла, -лә, -чы, -че
3) -дай, -дәй,-ча, -чә, -лап, -ләп
4) -ган, -гән, -ты, -те, -ачак, -әчәк

**10.** Кайсы сүз **тамыр, сүз ясагыч һәм бәйләгеч кушымчалар**дан тора?
1) яшьлек
2) утынлыкта
3) киләчәк
4) баручы

**11. Сыйфат ясалу тибы**на керә торган ысуллар кайсы төркемдә бирелгән?
1) уйланма, зурлама
2) кайгырма, тавышланма
3) юллама, кабартма
4) ясалма, чагыштырма

**12.** Җөмләдә аерып бирелгән исемнең килешен билгеләгез. *Гариф карышмады, тагын* ***баракка*** *китте.*
1) чыгыш килеше
2) юнәлеш килеше
3) төшем килеше
4) урын-вакыт килеше

**13. Минем** алмашлыгының төркемчәсе -
1) күрсәтү алмашлыгы
2) зат алмашлыгы
3) тартым алмашлыгы
4) билгеләү алмашлыгы

**14. Билгесез үткән заман хикәя фигыль кушымчалары**н күрсәтегез.
1) –ды, -де, -ты, -те
2) –ган, -гән, -кан, -кән
3) –ганчы, -гәнче, -канчы, -кәнче
4) –кач, -кәч, -гач, гәч.

**15.** Әйтү максаты ягыннан җөмләнең төрен билгеләгез. – *Җыеп ал!*
1) хикәя
2) сорау
3) боеру
4) тойгылы

**16.** *Дуслары* ***ялварса да****, ул кайтмады.* җөмләсендә аерып бирелгән сүз:
1) аергыч
2) хәл
3) тәмамлык
4) хәбәр

## 2 өлеш

Әлеге өлештәге биремнәргә җавапны җавап бланкына бирем санынннан уң якка беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифрны аерым шакмакка языгыз. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга кирәкми.

*Гомер узган саен күрәм: начар мин,*
*Языгым белеп* ***язмыштан*** *качалмыйм.*

**17.** Аерып бирелгән сүз җөмләнең нинди кисәге булып тора?
**18. Белеп** фигыленең төркемчәсен языгыз.
**19.** Бирелгән җөмләдән алмашлыкны күчереп языгыз.
**20. Языгым** сүзендә ничә аваз бар?